КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 12 июль г.Казань № 571

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Балалар һәм яшьләр ялын оештыру турында» 2016 ел, 31 март, 191 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Балалар һәм яшьләр ялын оештыру турында» 2016 ел, 31 март, 191 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 25 декабрь, 1031 нче; 2018 ел, 26 апрель, 294 нче; 2018 ел, 11 июнь, 460 нчы; 2018 ел, 29 декабрь, 1272 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Балалар һәм яшьләр ялын оештыру турындагы нигезләмәдә:

2 бүлекнең 2.5 нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.5. Кара диңгез буендагы лагерьда юнәлешле смена – бу иҗади сәләтле балалар, ирекләләр (волонтерлар), балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләре активы, укучылар, республика, бөтенроссия, халыкара конкурсларда, ярышларда һәм олимпиадаларда җиңүчеләр һәм приз алучылар, шулай ук тормышта авыр хәлдә калган балалар белән Кара диңгез буендагы стационар базада балалар һәм яшьләр тәүлек буе торып үткәрелә торган ял итү һәм белем бирү эшчәнлеге рәвеше.

Сменаның дәвамлылыгы җәйге чорда кимендә – 14 көн, көзге, кышкы һәм язгы чорларда кимендә җиде көн тәшкил итә.»;

3 бүлекнең 3.2 нче пунктындагы икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«югары белем бирүче мәгариф оешмалары студентлары;»;

4 бүлектә:

4.2 нче һәм 4.3 нче пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.2. Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре министрлыгы Татарстан Республикасы бюджетыннан финанслана торган түбәндәгеләрне оештыручы булып тора:

массакүләм физкультура чараларын;

иҗади сәләтле балалар һәм волонтерлар, балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләре активы әгъзалары, өстәмә гомуми белем бирү программаларын үзләштерүче укучылар өчен шәһәр читендәге ял лагерьларында, палатка тибындагы лагерьларда, шул исәптән Кара диңгез буендагы юнәлешле сменаларны;

җиде яшьтән 30 яшькә кадәрге (30 яшьне кертеп) тормышта авыр хәлдә калган балалар, яшьләр һәм балалар иҗтимагый берләшмәләре әгъзалары, халыкара, төбәкара, республика спорт чараларында җиңүчеләр, шулай ук Татарстан Республикасының халыкара һәм төбәкара килешүләрен тормышка ашыру кысаларында Россия Федерациясе субъектларыннан һәм якын һәм ерак чит илләрдән җибәрелә торган балалар һәм яшьләр ялын һәм аларның торгызу дәвалавын;

балансында лагерь булган коммерция оешмалары һәм коммерциягә карамаган оешмалар (муниципаль һәм дәүләт оешмаларыннан тыш) хезмәткәрләре балалары ялын

республика, бөтенроссия, халыкара конкурсларда, ярышларда һәм олимпиадаларда җиңүчеләр һәм приз алучылар, шулай ук тормышта авыр хәлдә калган балалар өчен Кара диңгез буендагы лагерьлардагы юнәлешле сменаларны;

профилактика исәбендә торучы балалар өчен юнәлешле сменаларны һәм үсмерләргә хәрби-патриотик тәрбия бирүгә юнәлдерелгән сменаларны.

Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы квартал саен финанслауның иң чик күләмнәрен Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре министрлыгына тиешле финанс елына Татарстан Республикасы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре күләмнәре, расланган бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләменнән чыгып кварталларга түбәндәгечә бүлеп ирештерә:

I квартал (5 февральгә кадәр) – 20 процент;

II квартал – 5 апрельгә кадәр) – 50 процент;

III квартал (5 июльгә кадәр) – 20 процент;

IV квартал (5 ноябрьгә кадәр) – 10 процент.

4.3. Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгы Татарстан Республикасы бюджетыннан финанслана торган түбәндәгеләрне сменаларны оештыручы булып тора:

ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар, опекунга алган һәм тәрбиягә бала алган гаиләләрдә тәрбияләнүче ятим балалар өчен шәһәр читендәге лагерьларда;

Татарстан Республикасының мәгариф оешмаларында белем алучы ятим балалар өчен сменаларны;

кадет мәктәпләрендә тәрбияләнүчеләр өчен сменаларны;

иҗади сәләтле балалар, ирекчеләр (волонтерлар), балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләре активы әгъзалары, Татарстан Республикасының халыкара һәм төбәкара килешүләрен тормышка ашыру кысаларында Россия Федерациясе субъектларыннан һәм якын һәм ерак чит илләрдән җибәрелә торган балалар һәм яшьләр, мәгариф оешмаларында тәрбияләнүчеләр өчен шәһәр читендәге ял лагерьларындагы юнәлешле сменаларны.

Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгы республика, бөтенроссия, халыкара конкурсларда, ярышларда һәм олимпиадаларда җиңүчеләр һәм приз алучылар өчен Кара диңгез буендагы лагерьлардагы юнәлешле сменаларны комплектлауда катнаша.

Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы квартал саен финанслауның иң чик күләмнәрен Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгына тиешле финанс елына Татарстан Республикасы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре күләмнәре, расланган бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләменнән чыгып кварталларга түбәндәгечә бүлеп ирештерә:

I квартал (5 февральгә кадәр) – 5 процент;

II квартал – 5 апрельгә кадәр) – 30 процент;

III квартал (5 июльгә кадәр) – 50 процент;

IV квартал (5 ноябрьгә кадәр) – 15 процент.»;

4.4 нче пунктында «шәһәр читендәге» сүзен төшереп калдырырга;

4.5 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы финанслауның иң чик күләмнәрен агымдагы елның 5 апреленә кадәр Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгына тиешле финанс елына Татарстан Республикасы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре күләмнәре, расланган бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә ирештерә.»;

4.6 нчы пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«иҗади сәләтле балалар, волонтерлар, балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләре активы әгъзалары, өстәмә гомуми белем бирү программаларын үзләштерүче укучылар өчен шәһәр читендәге ял лагерьларындагы һәм палатка тибындагы лагерьлардагы юнәлешле сменаларны;»;

түбәндәге эчтәлекле 4.7 нче пункт өстәргә:

«4.7. Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы финанслауның иң чик күләмнәрен агымдагы елның 5 апреленә кадәр Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына тиешле финанс елына Татарстан Республикасы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре күләмнәре, расланган бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә ирештерә.»;

6 бүлекнең 6.3 нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.3. Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан лагерьларда балалар һәм яшьләр ялы өчен ата-аналар түләве тормышта авыр хәлдә калган балалардан, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар өчен оешмаларда тәрбияләнүчеләрдән, хроник авырулары булган балалардан, шул исәптән бер ата-ана (яки законлы вәкилләре) озатып йөрүчесе булган балалардан, профилактика исәбендә торучы балалардан, республика, бөтенроссия, халыкара конкурсларында, ярышларда һәм олимпиадаларда җиңүчеләрдән һәм приз алучылардан, Татарстан Республикасының халыкара һәм төбәкара килешүләрен тормышка ашыру кысаларында Россия Федерациясе субъектларыннан һәм якын һәм ерак чит илләрдән җибәрелә торган балалардан һәм яшьләрдән, инвалид балалардан һәм хезмәт һәм ял лагерьларына җибәрелә торган балалардан алынмый.»;

10 бүлекнең 10.9 нчы пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10.9. Татарстан Республикасы муниципаль районының (шәһәр округының) башкарма комитеты смена тәмамланганнан соң җиде көн эчендә Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре министрлыгына шәһәр читендәге лагерьларда муниципаль яки дәүләт оешмалары хезмәткәрләре балалары өчен ял оештыру турында мәгълүмат җибәрә.»;

14 бүлектә:

14.2 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«14.2. Юнәлешле сменаларда катнашучылар шәһәр читендәге лагерьларга, палатка тибындагы лагерьларга, шул исәптән Кара диңгез буендагы лагерьларга юнәлешле сменада катнашучыдан яки юнәлешле сменада балигъ булмаган катнашучы өчен бер ата-анадан (яки законлы вәкилләрдән) алынган гариза нигезендә җибәрелә. Гаризалар юнәлешле сменаларны оештыручылар адресына (Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре министрлыгына, Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгына, Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгына, Татарстан Республикасы муниципаль районының (шәһәр округының) башкарма комитетына) (алга таба – юнәлешле сменаларны оештыручылар) бирелә. Профилактика исәбендә торучы, юнәлешле сменаларда катнашучы балалар шәһәр читендәге ял лагерьларына һәм палатка тибындагы лагерьларга Татарстан Республикасының муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башкарма комитетларының вәкаләтле органнары тарафыннан юнәлешле сменаларны оештыручылар адресына язылган заявка нигезендә җибәрелә.»;

14.3 нче пунктта «юнәлешле сменаларда катнашучы балалар исемлеге» сүзләрен «юнәлешле сменаларда катнашучылар исемлеге» сүзләренә алыштырырга;

14.4 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«14.4. Җыелма исемлектә юнәлешле сменаның һәр катнашучысы өчен түбәндәгеләр күрсәтелә:

юнәлешле сменада катнашучының фамилиясе, исеме, атасының исеме;

ата-аналарның (законлы вәкилләрнең) фамилиясе, исеме, атасының исеме (балигъ булмаган гражданнар өчен);

юнәлешле сменада катнашучының туган көне, җенесе;

туу урыны һәм теркәлү урыны;

балаларга өстәмә белем бирү оешмасы, юнәлешле сменада катнашучы була торган иҗтимагый оешма мөрәҗәгате яки юнәлешле сменада катнашучының казанышлар исемлеге (гариза бирү датасына кадәр килгән биш ел өчен икедән бишкә кадәр (дипломнар, грамоталар һ.б.).»;

14.5 нчы пунктның икенче абзацында «юнәлешле сменаларда катнашучы балалар исемлеге» сүзләрен «юнәлешле сменаларда катнашучылар исемлеге» сүзләренә алыштырырга;

14.6 нчы пунктның икенче абзацында «юнәлешле сменаларда катнашучы балалар» сүзләрен «юнәлешле сменаларда катнашучылар» сүзләренә алыштырырга;

14.7 нче пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Балалар һәм яшьләрнең юнәлешле сменаларда, шул исәптән палатка тибындагы лагерьларда булуы Россия Федерациясе законнары һәм балаларның ата-аналары (законлы вәкилләре) йә балигъ булган яшькә җиткән катнашучының үзе белән төзелгән шартнамә белән җайга салына. Урнаштыру, җайга салу, карап тоту һәм эшне оештыру шартлары санитария-эпидемиология кагыйдәләренә һәм гигиена нормативларына, янгынга каршы һәм террорчылыкка каршы куркынычсызлык таләпләренә туры килергә тиеш.»;

14.10 нчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«14.10. Шәһәр читендәге (туристлык) лагерьларда юнәлешле сменалар тәмамланганнан соң, юнәлешле сменаларны оештыручылар (Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре министрлыгыннан башка) җиде көн эчендә Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре министрлыгына шәһәр читендәге ял лагерьларында һәм палатка тибындагы лагерьларда үткәрелгән юнәлешле сменалар турында мәгълүмат җибәрә.»;

әлеге карар белән расланган Балалар һәм яшьләр ялын оештыру өчен Татарстан Республикасының муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү кагыйдәләрендә:

6 нчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Ял оештыру кампаниясен үткәрүгә субсидияләр Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округларының агымдагы елның 10 февраленә кадәр Министрлыкка Министрлык билгеләгән форма буенча җибәрә торган һәм аңа каникул вакытында балалар һәм яшьләр ялын оештыру буенча хезмәтләр күрсәтүче җирле үзидарә органнары карамагындагы муниципаль оешмалар исемлеге теркәлгән заявкалары нигезендә һәм муниципаль районының, шәһәр округының финанслашу өчен субсидия бирелә торган чыгым йөкләмәләрен билгели торган тиешле финанс елына (тиешле финанс елына һәм план чорына) бюджет турындагы муниципаль район, шәһәр округы карарыннан өземтә нигезендә бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләменнән чыгып кварталларга түбәндәгечә бүлеп бирелә:

I квартал (5 февральгә кадәр) – 25 процент;

II квартал (5 апрельгә кадәр) – 45 процент;

III квартал (5 июльгә кадәр) – 15 процент;

IV квартал (5 ноябрьгә кадәр) – 15 процент.»;

әлеге карар белән расланган Балалар һәм яшьләр ялын оештыру буенча ведомствоара комиссия составында:

Ведомствоара комиссия составыннан Р.В.Гайнетдиновны, С.А.Осиповны, В.Н.Циоманы чыгарырга;

Ведомствоара комиссия составына түбәндәгеләрне кертергә:

Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министрының беренче урынбасары Әлмир Рәшит улы Абашевны;

Россия Федерациясе Тикшерү комитетының тикшерү идарәсенә караган аеруча мөһим эшләрне тикшерү буенча өченче бүлек җитәкчесе Айрат Мәгъдүт улы Вәлиевны (килешү буенча).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин